МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

12.05.2026 ел № 199-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы уку йортларына укырга керү өчен гаризалар кабул итү һәм теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 21 декабрендәге 658-осн номерлы боерыгына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы норматив хокукый актын законнарга туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы уку йортларына укырга керү өчен гаризалар кабул итү һәм теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2022 елның 21 декабрендәге 658-осн номерлы боерыгына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль закон һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2022 елның 28 февралендәге 175 номерлы карары белән расланган Республика башкарма хакимият органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибе нигезендә боерык бирәм:»;

Урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы уку йортларына укырга керү өчен гаризалар кабул итү һәм теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын яңа редакциядә (кушымта итеп бирелә) бәян итәргә.

2. Юридик бүлеккә (Т.А.Барсукова) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Бу боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча үземне җаваплы итеп билгелим.

Министр Р.Ә. Кузюров

Татарстан Урман хуҗалыгы министрлыгының 2022 елның 21 декабрендәге 658-осн номерлы боерыгы белән расланды (Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2026 елның 12 маендагы 199-осн номерлы боерыгы редакциясендә)

## Урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы уку йортларына укырга керү өчен гаризалар кабул итү һәм теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты

### I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы уку йортларына укырга керү өчен гаризалар кабул итү һәм теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең әлеге Административ регламенты (алга таба – Административ регламент) урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы уку йортларына укырга керү өчен гаризалар кабул итү һәм теркәү буенча дәүләт хезмәте (алга таба – дәүләт хезмәте) күрсәтү стандартын һәм тәртибен билгели.

Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге әлеге Административ регламентның 1 нче кушымтасында китерелгән.

1.2. Мөрәҗәгать итүчеләр булып «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законда (алга таба – 273-ФЗ номерлы федераль закон) башкасы билгеләнмәгән булса, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы уку йортларына урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы уку йортларына укырга керү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән, төп гомуми белеме яисә урта гомуми белеме булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар, шул исәптән чит илдә яшәүче, ватандашлар (алга таба – мөрәҗәгать итүче) тора.

Мөрәҗәгать итүчеләр исеменнән законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче затлар (алга таба – мөрәҗәгать итүченең вәкиле) эш итә ала.

Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре:

14 яшькә җиткән затлар (уку өчен кандидатлар);

14 яшькә җитмәгән балигъ булмаган затларның (уку өчен кандидатларның) ата-аналары (законлы вәкилләре).

Мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) идентификаторлары әлеге Административ регламентның 2 нче кушымтасында китерелгән.

1.3. Дәүләт хезмәте мөрәҗәгать итүчегә мөрәҗәгать итүчеләрнең категорияләре (билгеләре) нигезендә күрсәтелә, алар турында белешмәләр

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (https://www.gosuslugi.ru) (алга таба – Бердәм портал), «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында (https://uslugi.tatarstan.ru) (алга таба – Республика порталы), «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) федераль реестры» федераль дәүләт мәгълүмат системасында (https://frgu.gosuslugi.ru) урнаштырыла.

## II. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 2.1. Күрсәтелә торган дәүләт хезмәте атамасы

2.1.1. Урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы уку йортларына укырга керү турында гаризаларны (алга таба – гариза) кабул итү һәм теркәү.

### 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның исеме

2.2.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен җаваплы орган – Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы (алга таба – Министрлык).

2.2.2. Дәүләт хезмәтен турыдан-туры учреждениеләр күрсәтә.

### 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

2.3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) гаризаны кабул итү һәм теркәү турында карар (әлеге Административ регламентка 6 нчы кушымта);

2) гаризаны кабул итүдән һәм теркәүдән баш тарту турында карар (әлеге Административ регламентка 7 нче кушымта).

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе буларак реестр язуын рәсмиләштерү каралмаган.

2.3.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе мөрәҗәгать итүчегә сайланган ысул нигезендә түбәндәгеләр (берелә) җибәрелә:

«Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) нигезендә учреждениенең вәкаләтле вазыйфаи затының көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталдагы яисә Республика порталындагы шәхси кабинетына (техник мөмкинлек булганда), мөрәҗәгать итүченең шәхси электрон почтасына;

мөрәҗәгать итүчегә учреждениедә шәхсән тапшыру юлы белән яисә тапшыру турында хәбәр итеп, заказлы хат җибәрү юлы белән кәгазьдә.

### 2.4. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакыты

2.4.1. Мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь вакыты гариза һәм документлар теркәлгән көннән алып биш эш көне тәшкил итә – мөрәҗәгать итүче шәхсән учреждениегә яисә почта аша мөрәҗәгать иткән очракта.

2.4.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең барлык категорияләре (билгеләре) өчен дәүләт хезмәте күрсәтүнең максималь вакыты гаризага эшләр номенклатурасы нигезендә номер һәм Бердәм порталда яисә Республика порталында шәхси кабинетта (техник мөмкинлек булганда) чагылдырыла торган «Документларны тикшерү» статусы бирелгән көннән башлап биш эш көне тәшкил итә – мөрәҗәгать итүче Бердәм порталда яисә Республика порталында (техник мөмкинлек булганда) шәхси кабинет аша мөрәҗәгать иткән очракта.

2.4.3. Беренче курска кабул итү өчен гаризалар 20 июньнән дә соңга калмыйча кабул ителә.

Көндезге уку формасына гаризалар 15 августка кадәр кабул ителә, ә буш урыннар булганда, документлар кабул итү агымдагы елның 25 ноябренә кадәр озайтыла.

Укырга керә торган затлардан билгеле бер иҗади сәләт, физик һәм (яки) психологик сыйфатларны таләп итә торган белгечлекләр (һөнәрләр) буенча белем бирү программалары буенча укырга керүче затлардан гаризалар 10 августка кадәр кабул ителә.

2.4.4. Көндезге һәм читтән торып уку формаларына гаризалар 1 декабрьгә кадәр кабул ителә.

### 2.5. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

2.5.1. Россия Федерациясе законнарында дәүләт хезмәтен күрсәткән өчен түләү алу каралмаган.

### 2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы рәсми мөрәҗәгатьне тапшырганда яисә мондый хезмәтләр күрсәтү нәтиҗәләрен алганда чират көтүнең максималь вакыты

2.6.1. Учреждениегә шәхсән гариза биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чират көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш.

2.6.2. Мөрәҗәгать итүчеләрнең аерым категорияләре өчен чират билгеләнмәгән.

### 2.7. Мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәте күрсәтү турында мөрәҗәгатен теркәүгә алу чоры

2.7.1. Учреждениегә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә яисә гаризаны почта аша җибәргәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гариза ул кергән көнне үк теркәлә.

2.7.2. Гаризаны Бердәм портал яисә Республика порталы (техник мөмкинлек булганда) аша җибәргәндә, мөрәҗәгать итүче гариза биргән көнне мөрәҗәгать итүченең шәхси кабинетында гаризаның алынуын раслый торган, аның теркәлү номеры һәм гариза биргән датасы күрсәтелгән хәбәр ала.

2.7.3. Ял (бәйрәм) көнендә электрон рәвештә кергән гариза аннан соңгы эш көненә теркәлә.

## 2.8. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

2.8.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр турындагы белешмәләр Министрлыкның, учреждениенең рәсми сайтында, Бердәм порталда яисә Республика порталында (техник мөмкинлек булганда) урнаштырыла.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең мөмкинлекле һәм сыйфатлы булу күрсәткечләре

2.9.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең һәркем файдалана алырлык булуы һәм сыйфат күрсәткечләре исемлеге Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда яисә Республика порталында (техник мөмкинлек булганда) урнаштырыла.

2.9.2. Мөрәҗәгать итүчеләргә дәүләт хезмәтеннән файдалану мөмкинлеген һәм аның сыйфатын Министрлыкның рәсми сайтында, Бердәм порталда яисә Республика порталында (техник мөмкинлекләр булганда) бәяләү мөмкинлеге тәэмин ителә.

## 2.10. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр, шул исәптән: күпфункцияле үзәкләрдә дәүләт хезмәте күрсәтүнең үзенчәлекләрен һәм электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү үзенчәлекләрен исәпкә ала торган; Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә дәүләт хезмәте турында белешмәләр бирү турында

2.10.1. Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган башка хезмәтләр каралмаган.

2.10.2. Комплекслы мөрәҗәгать составында дәүләт хезмәте күрсәтелми.

2.10.3. Дәүләт хезмәтен электрон рәвештә күрсәтү үзенчәлекләре.

Электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәткәндә мөрәҗәгать итүче хокуклы:

1) дәүләт хезмәтен күрсәтү тәртибе һәм сроклары турында Бердәм порталда, Республика порталында (техник мөмкинлек булганда) урнаштырылган мәгълүматны алырга;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле башка документларны, шул исәптән электрон үрнәкләре элегрәк «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль законның (алга таба – 210-ФЗ номерлы федераль закон) 16 статьясының 1 өлешендәге $7^2$ пункты нигезендә таныкланган документларны һәм мәгълүматны Бердәм порталдан, Республика порталыннан (техник мөмкинлек булганда) файдаланып тапшырырга;

3) дәүләт хезмәтен күрсәтү турында электрон рәвештә бирелгән гаризаны үтәү барышы турында белешмәләр алырга;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү сыйфатын бәяләүне гамәлгә ашырырга;

5) дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен электрон документ рәвешендә алырга;

6) Бердәм портал, Республика порталы (техник мөмкинлек булганда), дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелә торган органнар, аларның вазыйфаи затлары тарафыннан дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтелгәндә кабул ителгән карарларга һәм кылынган гамәлләргә (гамәл кылмауга) судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү процессын тәэмин итә торган федераль дәүләт мәгълүмат системасы порталы ярдәмендә учреждение, шулай ук аның хезмәткәрләре карарына һәм гамәленә (гамәл кылмавына) шикаять бирергә.

Гаризаны формалаштыру, гаризаны өстәмә рәвештә нинди дә булса башка рәвешле тапшыру зарурлыгыннан тыш, Бердәм порталда һәм Республика порталында (техник мөмкинлек булганда) гаризаның электрон рәвешен тутыру юлы белән гамәлгә ашырыла.

Мөрәҗәгать итүче Бердәм порталда яисә Республика порталында (техник мөмкинлек булганда) электрон рәвештә гариза бирү өчен түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда яисә Республика порталында (техник мөмкинлек булганда) авторизация уза;

Бердәм порталда яисә Республика порталында (техник мөмкинлек булганда) электрон гариза рәвешен ача;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри булган белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза рәвешен тутыра;

электрон рәвештәге документларны яки электрон документ үрнәкләрен электрон гариза рәвешенә беркетә;

электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтү шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм риза булу фактын раслый (электрон гариза рәвешендә ризалык турында тиешле тамга билгели), китерелгән белешмәләрнең дөреслеген раслый;

тутырылган электрон гаризаны җибәрә (электрон гариза рәвешендәге тиешле төймәгә баса);

электрон гаризаның җибәрелүе турында белдерү ала.

Гаризаны формалаштырганда түбәндәгеләр тәэмин ителә:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле гаризаның һәм башка документларның күчермәләрен алу һәм саклап кую;

2) электрон гариза рәвеше күчермәсен кәгазьдә бастырып чыгару;

3) файдаланучы ихтыярына карап, шул исәптән күрсәткечләрне гаризаның электрон рәвешенә ялгыш керткәндә һәм яңадан кертү зарурлыгы булганда да, теләсә кайсы вакытта электрон гариза рәвешенә элегрәк кертелгән күрсәткечләрне саклау;

4) «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик бәйләнешен тәэмин итүче инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасында

(https://esia.gosuslugi.ru) (алга таба – БИАС) урнаштырылган мәгълүматлардан һәм Бердәм порталда, Республика порталында (техник мөмкинлек булганда) урнаштырылган мәгълүматлардан файдаланып, БИАС булмаган мәгълүматларга кагыла торган өлештә мөрәҗәгать итүче мәгълүматлар кертә башлаганчыга кадәр гаризаның электрон рәвешендәге кырларны тутыру;

5) элегрәк кертелгән мәгълүматларны югалтмыйча, электрон гариза рәвешен тутыруның теләсә кайсы этапларына яңадан әйләнеп кайту;

6) кимендә бер ел дәвамында элегрәк тапшырылган гаризаларны мөрәҗәгать итүче тарафыннан карау мөмкинлеге, шулай ук өлешчә формалаштырылган гаризалар буенча – кимендә өч ай дәвамында.

2.10.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

2.10.5. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кулланыла торган мәгълүмат системалары исемлеге:

1) Бердәм портал;

2) Республика порталы (техник мөмкинлек булганда);

3) «Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы.

2.10.6. Балигъ булмаган балага карата дәүләт хезмәте күрсәтүнең кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән нәтиҗәләре, әгәр мөрәҗәгать итүче дәүләт хезмәтен күрсәтү турында гариза биргән вакытта балигъ булмаган балага карата дәүләт хезмәте күрсәтүнең сорала торган нәтиҗәләрен шәхсән үзе алырга теләк белдергән булса, балигъ булмаган баланың башка законлы вәкиленә бирелми.

Дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен мөрәҗәгать итүче булмаган балигълык яшенә җитмәгән затның законлы вәкиле алу кирәк булган очракта, гаризада мөрәҗәгать итүче тарафыннан балигъ булмаган затның дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсен алу өчен кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелеп вәкаләт бирелгән башка законлы вәкиленең фамилиясе, исеме, атасының исеме (булган очракта), шәхесен таныклаучы документ турында белешмәләр күрсәтелә.

Гаризада мөрәҗәгать итүче булмаган балигъ булмаган затның законлы вәкиле тарафыннан кәгазь чыганактагы документ рәвешендә рәсмиләштерелгән балигъ булмаган затка карата дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алу турында белешмә күрсәтелгән очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтү нәтиҗәсе аның өчен мөрәҗәгать итү көнендә бу затка үзенең шәхесен таныклаучы документ күрсәтелгәндә бирелә.

2.10.7. Дәүләт хезмәте дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгендә күрсәтелми.

### 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.11.1. Дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге әлеге Административ регламентның 3 нче кушымтасында китерелгән, түбәндәгеләргә бүлеп:

1) мөрәҗәгать итүче үзе тапшыра торган, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен

кирәкле документлар;

2) дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле, мөрәҗәгать итүче үз инициативасы белән тапшырырга хокуклы булган, ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар.

2.11.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаның рәвеше әлеге Административ регламентның 5 нче кушымтасында китерелгән.

## 2.12. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору яисә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

2.12.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге:

1) гаризаның дәүләт хезмәте күрсәтүгә вәкаләтле булмаган органга тапшырылуы;

2) мөрәҗәгать итүченең әлеге Административ регламентның 3 нче кушымтасының 1 бүлегендә күрсәтелгән документларның тулы булмаган комплектын тапшыруы;

3) мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның үз көчен югалтуы;

4) мөрәҗәгать итүче тарафыннан тапшырылган документларның тексты законнарда билгеләнгән тәртиптә таныкланмавы, аларда чистарту һәм төзәтү урыннары булу;

5) кәгазь чыганактагы документларда дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларда булган мәгълүматны һәм белешмәләрне тулы күләмендә файдалану мөмкинлеген бирми торган бозык урыннар булуы;

6) Бердәм портал яисә Республика порталы ярдәмендә (техник мөмкинлек булганда) документ текстын тулы күләмдә укырга һәм (яисә) документның реквизитларын танырга мөмкинлек бирми торган документларның электрон рәвешләрен тапшыру;

7) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гаризаны һәм хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны билгеләнгән таләпләрне бозып, электрон рәвештә бирү;

8) элек җибәрелгән гариза буенча дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты әле узмаган, элегрәк теркәлгән гаризага охшаш гариза алынган очракта.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза Бердәм порталда, Республика порталында (техник мөмкинлек булганда), учреждениенең һәм Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгарылган дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, документларны кабул итүдән баш тарту тыела.

2.12.2 Дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр каралмаган.

2.12.3. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге:

1) гаризада һәм аңа теркәп тапшырылган документларда каршылыклы мәгълүматлар булуы;

2) мөрәҗәгать итүченең әлеге Административ регламентның 1.2 пунктында күрсәтелгән гариза бирү хокукына ия затлар даирәсенә туры килмәве;

3) гаризаның мөрәҗәгать итүче мәнфәгатьләрен яклауга вәкаләте булмаган зат тарафыннан бирелүе;

4) гаризаны мөрәҗәгать итүче инициативасы буенча кире алу;

5) медицина ягыннан каршылыклар булуы.

2.12.4. Мөрәҗәгать итүче учреждениегә ирекле рәвештә язылган гариза нигезендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартырга хокуклы. Гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту турындагы карарны теркәп, мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту факты учреждениедә теркәлә. Дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту мөрәҗәгать итүченең дәүләт хезмәтен күрсәтүне сорап учреждениегә кабат мөрәҗәгать итүенә комачауламый.

2.12.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны һәм дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге һәм дәүләт хезмәтен күрсәтүне туктатып тору яки дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге әлеге Административ регламентның 4 нче кушымтасында китерелгән.

2.12.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза Бердәм порталда, Республика порталында (техник мөмкинлек булганда), учреждениенең һәм Министрлыкның рәсми сайтында бастырып чыгарылган дәүләт хезмәте күрсәтү сроклары һәм тәртибе турындагы мәгълүмат нигезендә бирелгән очракта, дәүләт хезмәтен күрсәтүдән баш тарту тыела.

2.12.7. Дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарткан очракта, учреждение мөрәҗәгать итүчегә мондый баш тартуның сәбәпләре турында, кире кагуга сәбәп булган документлар һәм мәгълүмат исемлеген күрсәтеп, шулай ук федераль законнарда һәм (яисә) башка норматив хокукый актларда билгеләнгән дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуга китергән таләпләр исемлеген күрсәтеп, хәбәр итә.

## III. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм чорлары

### 3.1. Административ процедуралар исемлеге

3.1.1. Мөрәҗәгать итүче һәм (яисә) мөрәҗәгать итүченең объектлары һәм (яисә) башка объектлар турында белешмәләрне, шулай ук мөрәҗәгать итүченең белемнәрен (күнекмәләрен) аларның Россия Федерациясе законнары таләпләренә туры килү-килмәвен бәяләү (дәүләт хезмәте күрсәтү (күрсәтүдән баш тарту) турында карар кабул итү процедурасы кысаларында тикшерелә торган таләпләрдән тыш) үткәрелә торган административ процедураны, дәүләт хезмәте күрсәтү турында карар кабул ителгәннән соң мөрәҗәгать итүчегә карата чикләнгән ресурсны (шул исәптән җир кишәрлекләрен, радиоешлыкларны, квоталарны) бүлүне күздә тоткан административ процедураны, мөрәҗәгать итүчедән өстәмә белешмәләр алуның административ процедурасын, бер дәүләт хезмәте күрсәтү кысаларында ике

һәм аннан да күбрәк мәртәбә кабатлау рөхсәт ителә торган дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып торуның административ процедурасын гамәлгә ашыру каралмаган.

3.1.2. Дәүләт хезмәте күрсәтү түбәндәге административ процедуралардан тора:

1) мөрәҗәгать итүчене профильләштерү;

2) гаризаны, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүматны кабул итү;

3) ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек;

4) дәүләт хезмәте күрсәтү турында (күрсәтүдән баш тарту турында) карар кабул итү;

5) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен бирү.

### 3.2. Дәүләт хезмәтен алгарышлы (проактив) режимда күрсәтү

3.2.1. Дәүләт хезмәтен алгарышлы (проактив) режимда күрсәтү гамәлгә ашырылмый.

## IV. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү ысуллары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы гаризаны карау статусын үзгәртү турында мөрәҗәгать итүчегә хәбәр итү түбәндәгечә гамәлгә ашырыла:

учреждениегә шәхсән мөрәҗәгать иткәндә;

автомат режимда мөрәҗәгать итүченең Бердәм порталдагы яисә Республика порталындагы (техник мөмкинлек булганда) шәхси кабинетына;

программаларын гамәлгә
ашыручы уку йортларына
укырга керү өчен гаризалар
кабул итү һәм теркәү буенча
дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
1 нче кушымта

**Шартлы билгеләр һәм кыскартулар исемлеге**

1. Административ регламент – Урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы уку йортларына укырга керү өчен гаризалар кабул итү һәм теркәү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламенты;
2. дәүләт хезмәте – урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы уку йортларына укырга керү өчен гаризалар кабул итү һәм теркәү буенча дәүләт хезмәте;
3. мөрәҗәгать итүче – «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль законда (алга таба – 273-ФЗ номерлы федераль закон) башкасы билгеләнмәгән булса, Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы уку йортларына урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы уку йортларына укырга керү турында гариза белән мөрәҗәгать иткән, төп гомуми белеме яисә урта гомуми белеме булган Россия Федерациясе гражданнары, чит ил гражданнары, гражданлыгы булмаган затлар, шул исәптән чит илдә яшәүче, ватандашлар;
4. мөрәҗәгать итүченең вәкиле – законнарда билгеләнгән тәртиптә бирелгән ышанычнамә нигезендә эш итүче затлар;
5. учреждение – Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы карамагындагы урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы уку йортлары;
6. гариза – урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы уку йортларына укырга керү өчен гариза;
7. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы;
8. Бердәм портал – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (https://www.gosuslugi.ru);
9. Республика порталы – «Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр порталы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы (https://uslugi.tatarstan.ru);
10. БИАС – «Электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик үзара хезмәттәшлеген тәэмин итүче инфраструктурада бердәм идентификация һәм аутентификация системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы (https://esia.gosuslugi.ru);
11. 210-ФЗ номерлы федераль закон – «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы федераль

закон;

12. 63-ФЗ номерлы федераль закон – «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы федераль закон;

13. 273-ФЗ номерлы федераль закон – «Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы федераль закон;

14. 457 номерлы тәртип – Россия Федерациясе Мәгариф министрлыгының 2020 елның 2 сентябрендәге 457 номерлы боерыгы белән расланган Урта һөнәри белем бирүнең уку-укыту программалары буенча укырга кабул итү тәртибе.

программаларын гамәлгә ашыручы
уку йортларына укырга керү өчен
гаризалар кабул итү һәм теркәү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
2 нче кушымта

Мөрәҗәгать итүченең категорияләре (билгеләре) идентификаторы

| № | Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе | Мөрәҗәгать итүченең аерым билгесе исеме | Мөрәҗәгать итүченең аерым билгесе идентификаторы |
|---|---|---|---|
| 1. | Урта һөнәри белем бирү программаларын гамәлгә ашыручы уку йортларына укырга керү өчен гариза кабул итү һәм теркәү турында карар | мөрәҗәгать итүче – Россия Федерациясе гражданины | 1А |
| | | мөрәҗәгать итүче – Россия Федерациясе гражданинының вәкиле | 2А |
| | | мөрәҗәгать итүче – чит ил гражданины, гражданлыгы булмаган зат, шул исәптән чит илдә яшәүче ватандаш | 3А |
| | | мөрәҗәгать итүченең вәкиле – чит ил гражданины, гражданлыгы булмаган зат, шул исәптән чит илдә яшәүче ватандаш | 4А |

Урта һөнәри белем бирү

программаларын гамәлгә ашыручы
уку йортларына укырга керү өчен
гаризалар кабул итү һәм теркәү
буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең
административ регламентына
3 нче кушымта

Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

| № | Мөрәҗәгать итүче тапшыра торган документлар төрләренең шифрын ачу, төркемнән документлар саны | Мөрәҗәгать итүче билгесе идентификаторы | Тапшыру ысулы | Документ төре | Башка таләпләр |
|---|---|---|---|---|---|
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 |
| **1. Мөрәҗәгать итүче үзе тапшыра торган, дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен кирәкле документлар** | | | | | |
| 1. | рус телендә гариза | **1А, 2А, 3А, 4А** | учреждениегә шәхсән | төп нөсхә | - |
| | | | Бердәм портал, Республика порталы (техник мөмкинлек булганда) | 63-ФЗ номерлы федераль закон таләпләре нигезендә имзаланган (таныкланган) | |
| | | | почта юлламасы белән; | төп нөсхә | |
| 2. | мөрәҗәгать итүче вәкиленең вәкаләтләрен таныклаучы документ | **2А, 4А** | учреждениегә шәхсән | әгәр күчермә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, документның төп нөсхәсен күрсәтеп, күчермә | - |
| | | | Бердәм портал, Республика порталы (техник мөмкинлек булганда) | документның электрон дубликаты (документларның электрон рәвешләре) pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf форматларында файллар рәвешендә җибәрелә | |
| | | | почта юлламасы белән; | документның Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә | |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | таныкланган күчермәсе | |
| 3. | шәхесне раслаучы документы | **1А, 2А, 3А, 4А** | учреждениегә шәхсән | әгәр күчермә Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә таныкланмаган булса, документның төп нөсхәсен күрсәтеп, күчермә | Россия Федерациясендә чит ил гражданинының шәхесен таныклаучы документ (чит дәүләт гражданнары өчен) тапшырылырга мөмкин |
| | | | Бердәм портал, Республика порталы (техник мөмкинлек булганда) | шәхесне таныклаучы документтан белешмәләр БАИС системасында исәпкә кую язуын раслаганда тикшерелә | |
